РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«07» 12 2018 г. №936

2019 елга муниципаль торак контроле

өлкәсендә мәҗбүри закончалык таләпләрен

бозуны кисәтү программасын раслау турында

2008 елның 26 декабрендәге «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда, юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында»гы 294-ФЗ номерлы Федераль законның 8.2 статьясындагы 1 өлеше нигезендә, муниципаль торак контроле функцияләрен гамәлгә ашыру максатларында, Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты, бирә:

1. 2019 елга муниципаль торак контроле өлкәсендә законнарныц мәҗбүри таләпләрен бозуларны профилактикалау Программасын (Кушымта) расларга.

2. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Ютазы муниципаль районыныц рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче С.П. Самонина

А.Н.Захаров
2-81-49

Кушымта
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
________2018 ел №______

**2019 елга муниципаль торак контроле өлкәсендә мәҗбүри таләпләрне бозуны кисәтү ПРОГРАММАСЫ**

## 1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге программа торак закончалыгы кысаларында территориаль орган карамагындагы субъектлар тарафыннан мәҗбүри таләпләрне бозуны кисәтү һәм федераль законнарда һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында, Ютазы муниципаль районының муниципаль хокукый актларында билгеләнгән муниципаль торак фондына зыян килү куркынычын киметү максатларында, җирле үзидарә органнары, юридик затлар, аларның җитәкчеләре һәм башка вазыйфаи затлар, шәхси эшмәкәрләр, гражданнар тарафыннан мөмкин булган кагыйдә бозуларны кисәтү, закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычын киметү максатларында эшләнде. 1.2.Мәҗбүри таләпләрне бозуларны кисәтү муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру кысаларында үткәрелә.

1.3. Программаның максаты булып тора:

1.3.1. Контроль астындагы субъектлар тарафыннан мәҗбүри закончалык таләпләрен бозуны да кертеп, тәртип бозуларны кисәтү, мәҗбүри таләпләрне бозуга китерергә мөмкин булган сәбәпләрне, факторларны һәм шартларны да кертеп.

1.4. Программаның бурычлары булып тора:

1.4.1.Мәҗбүри таләпләрне бозуны профилактикалау системасын профилактик эшчәнлекне активлаштыру юлы белән ныгыту.

1.4.2.Мәҗбүри таләпләрне бозуга китерә торган сәбәпләрне, факторларны һәм шартларны ачыклау.

1.4.3.Муниципаль торак фондыннан файдаланганда, юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр җитәкчеләренең, гражданнарның хокукый аңын һәм хокукый культурасын арттыру.

1.5. Программа 2019 елга эшләнгән.

1.6.Муниципаль торак контролен гамәлгә ашырганда профилактик чаралар субъектлары булып юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр, Ютазы муниципаль районы территориясендә муниципаль торак урыннарны биләүче гражданнар тора.

1.7. Ютазы муниципаль районы башкарма комитеты, барлык дәрәҗәдәге закончалык белән билгеләнгән хокук бозуларны кисәтү кысаларында, юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр һәм гражданнар арасыннан вәкилләр кабул итә, шулай ук торак законнарын үтәү мәсьәләләре буенча консультацияләр үткәрә һәм аңлатмалар бирә.

## 2 бүлек. Хокук бозуларны кисәтү буенча чаралар

| № т/б | Мәҗбүри таләпләрне бозуны кисәтү буенча чара | Башкару вакыты | Җаваплы вазифаи зат |
|---|---|---|---|
| 1. | Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында муниципаль торак контроле предметы булган мәҗбүри таләпләрне үз эченә алган норматив хокукый актлар яки аларның аерым өлешләре, шулай ук тиешле норматив хокукый актлар текстлары исемлеген урнаштыру | Яңа норматив-хокукый актларны кабул итүгә карап (алга таба - НХА), гамәлдәге НХАларга үзгәрешләр кертү | Муниципаль торак контролен гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазифаи затлар |
| 2. | Мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә мәгълүмат бирүне гамәлгә ашыру, шул исәптән мәҗбүри таләпләрне үтәү буенча кулланма эшләү һәм массакүләм мәгълүмат | Ел дәвамында (зарурлыгына карап) | Муниципаль торак контролен гамәлгә ашыруга вәкаләтле |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | чараларында бастырып чыгару һәм башка ысуллар белән аңлату эшләрен башкару | | вазифаи затлар |
| 3. | Мәҗбүри таләпләр үзгәргән очракта: гамәлдәге актларга кертелгән мәҗбүри таләпләрне билгели торган яңа норматив - хокукый актларны, аларның гамәлгә керү сроклары һәм тәртибен билгели торган мәҗбүри таләпләрне, шулай ук мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен тәэмин итүгә юнәлдерелгән кирәкле оештыру техник чараларын үткәрү турында рекомендацияләр әзерләү һәм тарату | Ел дәвамында (зарурлыгына карап) | Муниципаль торак контролен гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазифаи затлар |
| 4. | 2008 елның 26 декабрендәге «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында" 294 – ФЗ номерлы Федераль законның 8.2 статьясындагы 5-7 өлешләре нигезендә мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтүләр ясау, әгәр башка тәртип федераль законда билгеләнмәгән булса | в течение года (по мере необходимости ) | Муниципаль торак контролен гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазифаи затлар |
| 5. | Муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру тәҗрибәсен гомумиләштерү һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында тиешле гомумиләштерүләр урнаштыру, шул исәптән еш очрый | 2019 елның4 кварталы | Муниципаль торак контролен гамәлгә ашыруга |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | торган очракларны, хокук бозуларны булдырмау максатларында юридик затлар, шәхси эшкуарлар тарафыннан кабул ителергә тиешле чараларга карата мәҗбүри таләпләрне бозу очраклары күрсәтеп | | вәкаләтле вазифаи затлар |
| 6. | 2020 елга муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалау программасын эшләү һәм раслау | 2019 елның 25 декабренә кадәр | Муниципаль торак контролен гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазифаи затлар |